| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>ГЛАВА<br>Алькеевского сельского<br>поселения<br>Азнакаевского муниципального<br>района<br><br>Пер.Советский,44а,<br>423309 Тел. ( 885592) 37-4-23 | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>Азнакай муниципаль районы<br>Әлкәй авыл җирлеге<br>советы<br>БАШЛЫГЫ<br><br>Пер.Советский, 44а<br>Әлкәй авылы, 423309<br>Тел. (885592) 37-4-23 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“11” ноября 2019 ел №39

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Совет урамы 1 йорттан 98 йортка кадәр, Школьная урамы 1 йорттан 42 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 23 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:Тау өсте урамы урамы 1 йорттан 26 йортка кадәр, Тау өсте тыкрыгы урамы 19 йорттан 28 йортка кадәр, Профсоюз урамы 1 йорттан 18 йортка кадәр, Яңа урамы 1а йорттан 3а йортка кадәр.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 22 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг.тән 19.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 19.00 сәг.тән 20.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Әлкәй авылы, Совет ур.34 йорт, Әлкәй авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Әлкәй авылы, Пер.Совет урамы, 44а йорт;

- сайлау хокукына ия булган Әлкәй торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Әлкәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел”, “Инвалидлар көне”;
- Әлкәй авылында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй авылында юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй авылында территорияләрне чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш(щебенка) җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү(чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй авылында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй авылында зиратларга дератизация уздыру.

« РИЗА» «КАРШЫ”

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авылы,пер.Совет ур.,44а йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: С.З.Зиннурова